**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Светлоозерского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Якты Күл авыл**
**җирлегенең**
**башкарма комитеты**

ул. Фардеева, д.15, с. Светлое Озеро,
Заинский район, 423538

Фардеев урамы, 15нче йорт, Якты Күл
авылы, Зәй районы, 423538

Телефон, факс 68-2-88. Электронный адрес: Svoz.Zai@tatar.ru, сайт:
http://zainsk.tatarstan.ru/rus/svetloozerskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**от 31.01.2023 ел.**

**КАРАР**
**№ 2**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 27 маендагы 8 номерлы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 27 маендагы 8 номерлы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган (Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 10 декабрендәге 19 номерлы, 2020 елның 29 июлендәге 16 номерлы, 2020 елның 15 октябрендәге 19 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.1 пунктына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 14 пунктны өстәргә:

«14) нотариаль таныкланган килешүләрнең эчтәлеген белдерә торган документларның дубликатларын бирергә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **З. З. Мөхтәров**